**ГЛАВА ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **КАРАР**

«15» октябрь 2024 ел № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районының Фомкино авылы җирлегенә керүче Фома авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2024 елның 28 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы, Школьная урамы, 15нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару);

- Фома авылында урамнарны яктырту җайланмасы;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Фомкино торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы карап тоту).»

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фомкино авылындагы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов